РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» 12 2018 г. №1031

“2019-2021 елларга Ютазы районы яшьләре”

муниципаль программасын раслау турында

2013 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 14 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы яшьләренең социаль активлыгын арттыруга шартлар тудыру, авыл яшьләренең рухи, физик һәм иҗади үсешенә ярдәм итү, яшьләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеге, аларның мәнфәгатьләрен һәм проблемаларын ачыклау максатыннан, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2021 елларга Ютазы районы яшьләре» муниципаль программасын кушымта нигезендә расларга.

2. “Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге” МКУга программа чаралары үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче С.П. Самонина

М.Н. Садриева
2-81-97

**Татарстан Республикасы Ютазы**

**муниципаль районы Башкарма комитеты**

**карары белән расланды**

**___ ______2018 ел №**

# “2019 – 2021 елларга Ютазы районы яшьләре" муниципаль программасы

## I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

### 1 бүлек. “2019 – 2021 елларга Ютазы районы яшьләре” муниципальной программасы паспорты

| | |
|---|---|
| **Программаның исеме** | «2019 – 2021 елларга Ютазы районы яшьләре» муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| **Программаны эшләү өчен нигез** | -1999 елның 24 июнендәге «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында” 20-ФЗ номерлы Федераль закон»;<br>- 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принңиплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон»;<br>- 2014 елныц 29 ноябрендәге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең дәүләт яшьләр сәясәте нигезләрен раслау турында" 2403-р номерлы күрсәтмәсе;<br>- 2015 елның 29 маендагы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясендә Тәрбия үсеше стратегиясен раслау турында" 996-р номерлы күрсәтмәсе;<br>- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 12 декабрендәге «2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең дәүләт яшьләр сәясәте нигезләрен гамәлгә ашыру буенча чаралар планы турында" 2570-р номерлы күрсәтмәсе;<br>- 2015 елның 30 декабрендәге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2016 - 2020 елларга Россия Федерациясе гражданнарына патриотик тәрбия бирү "дәүләт программасы турында" 1493 номерлы карары;<br>- "1993 елның 19 октябрендәге «Татарстан Республикасында яшьләр һәм дәүләт яшьләр сәясәте турында” 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы законы |
| **Программаны төп эшләүче** | «Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге” МКУ |
| **Программаны** | Программаны төп үтәүче булып «Ютазы муниципаль |

<table>
<tr><td>үтәүчеләр</td><td>районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге” МКУ төра</td></tr>
<tr><td>Программаның максаты</td><td>Максаты – яшьләр арасында Ютазы районының үзенә җәлеп итүчәнлеген арттыру һәм аның социаль активлыгын үстерү өчен шартлар тудыру</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td>- район территориясендә яшәүче барлык категория яшьләрнең мәнфәгатьләрен һәм проблемаларын өйрәнү;<br>- район чикләрендә үсеш мөмкинлекләре турында яшьләрнең хәбәрдарлыгын арттырырга сәләтле чаралар системасын эшләү;<br>- яшьләрне хакимият органнары белән хезмәттәшлек итү юлы белән Ютазы районының социаль-икътисади үсешендә системалы катнашуына җәлеп итү;<br>- җирле үзидарә органнарында киләчәктә эшләү өчен яшьләрнең иң актив өлешен ачыклау.</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары</td><td>2019-2021 еллар</td></tr>
<tr><td>Елларга бүлеп Программаны финанслауның күләме һәм чыганаклары</td><td>Программаны финанслау муниципаль, республика бюджетлары хисабына һәм җәлеп ителгән акчалар хисабына гамәлгә ашырыла.
<table>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру еллары</td><td>1-нче ел/ мең сум</td><td>2- нче ел/ мең сум</td><td>3- нче ел/ мең сум</td><td>Барлыгы мең сум</td></tr>
<tr><td>Барлык чыганаклар буенча</td><td>5 185,1</td><td>5 185,1</td><td>5185,1</td><td>15 555,3</td></tr>
</table>
Программаны тормышка ашыруга тотылган акчаларның күләме район һәм республика бюджетлары, Ютазы муниципаль районы территориясендә инфляция процесслары һәм ул икътисадый вәзгыять мөмкинлекләреннән чыгып төгәлләштерелергә һәм аңа төзәтмәләр кертелергә мөмкин</td></tr>
<tr><td>Программаның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре</td><td>Программа районның социаль-икътисадый үзгәртеп коруларында яшьләрнең ролен арттырырга; мәдәни – сәламәтләндерү, интеллектуаль, иҗади, патриотик һәм профилактик юнәлеш программасына җәлеп ителгән яшьләр санын үстерергә; авыл һәм эшче яшьләрнең иҗади активлыгын һәм эшлеклелеген</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | арттырырга; яшьләрнең интеллектуаль, әхлакый һәм иҗади потенциалын, гражданлык һәм патриотлыкны арттырырга мөмкинлек бирәчәк |
| **Программаны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы** | «Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре спорт һәм туризм бүлеге» МКУ |

## 2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа ысулы белән чишүне нигезләү

Яшьләр - яшь үзенчәлекләре, социаль хәле нигезендә аерылып торган социаль-демографик төркем һәм специфик мәнфәгатьләре һәм кыйммәтләре белән характерлана. Әлеге төркем 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге, ә кайбер Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән очракларда - Россия Федерациясендә яки чит илләрдә яшәүче (Россия Федерациясе гражданнары һәм ватандашлары) 35 яшькә кадәрге һәм өлкәнрәк затларны үз эченә ала.

Рәсми статистика мәгълүматларына ярашлы, 2018 елның 1 гыйнварына Ютазы муниципаль районы халкының чагыштырма дәрәҗәсе 20 539 кеше тәшкил итте, халыкның гомуми саныннан 18,5% - ул - 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләр. Ел саен бу сан кими бара.

1 гыйнварга бөтен халык саны

| **Күрсәткечләр** | **Үлчәү берәмлеге** | **2015** | **2016** | **2017** | **2018** |
|---|---|---|---|---|---|
| Барлыгы | кеше | 21094 | 20965 | 20735 | 20539 |
| Хатын-кызлар | | 11250 | 11129 | 10985 | 10855 |
| Ирләр | | 9844 | 9836 | 9750 | 9684 |

1 гыйнварга җенесләр буенча 14-30 яшьлек яшьләр саны

| **Күрсәткечләр** | **Үлчәү берәмлеге** | **2015** | **2016** | **2017** | **2018** |
|---|---|---|---|---|---|
| Барлыгы | кеше | 4132 | 4052 | 3916 | 3791 |
| Хатын-кызлар | | 1989 | 1909 | 1838 | 1757 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Ир-егетләр | | 2143 | 2143 | 2078 | 2034 |

Күпчелек вакытта халык саны кимүе яшьләрнең башка территорияләргә китүе сәбәпле күзәтелә.

1 гыйнварга районнан киткән халыкның гомуми саны

| **Күрсәткечләр** | **Үлчәү берәмлеге** | **2015** | **2016** | **2017** |
|---|---|---|---|---|
| Барлыгы | кеше | 863 | 880 | 822 |
| Хатын-кызлар | | 492 | 465 | 447 |
| Ир-егетләр | | 371 | 415 | 375 |

1 гыйнварга районнан киткән 14-30 яшьлек яшьләрнең гомуми саны

| **Күрсәткечләр** | **Үлчәү берәмлеге** | **2015** | **2016** | **2017** |
|---|---|---|---|---|
| Барлыгы | кеше | 359 | 334 | 401 |
| Хатын-кызлар | | 289 | 189 | 177 |
| Ир-егетләр | | 130 | 145 | 129 |

2017 елда Ютазы районыннан барлыгы 822 кеше миграцияләнгән, бу район халкының гомуми санынннан 4% тәшкил итә (20 735 кеше). Аларның 49% ы - 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләр. Башка шәһәрләргә һәм төбәкләргә, ир-атлар һәм хатын-кызлар тигез дәрәҗәдә китә.

Моннан төп проблема – Ютазы районыннан яшьләр китүе проблемасы барлыкка килә.

Яшьләр миграциясенең төп сәбәпләре: эш һәм карьера үсеше мөмкинлекләре булмау, хезмәт хакының түбән дәрәҗәсе. Вазгыятьне ял итү инфраструктурасы булмау, үз территорияләре чикләрендә үзләрен күрсәтү мөмкинлеге булмау да катлауландыра. Районның яшь кешеләре зур уку учреждениеләре уңышлы эшләгән, шулай ук диверсификацияләнгән хезмәт базары булган зур шәһәрләргә тартыла.

Бу шартларда миграция сәясәтенә аерым игътибар бирү, район чикләрендә яшьләрнең хәбәрдарлыгын арттырырга сәләтле чаралар системасын эшләү аерым әһәмияткә ия, чөнки актив яшьләрнең саны кимү районныц социаль-икътисади торгынлыгына китерәчәк.

## 3 бүлек. Программаның максаты һәм бурычлары

Максат - яшьләр арасында Ютазы районының җәлеп итүчәнлеген арттыру һәм аның социаль активлыгын күтәрү өчен шартлар тудыру.

S – конкретлык - районның яшьләрнең булачак яшәү урыны сыйфатында җәлеп итүчәнлеген арттыру.

M – үлчәнүчәнлек - районнан китүче яшьләр санын киметү.

A – ирешергә мөмкинлек – яшьләргә һөнәри үсеш һәм районда үз потенциалын тормышка ашыру мөмкинлекләре турында мәгълүмат бирү.

R – актуальлек - район яшьләренә аларның социаль активлыгын кочәйтү очен шартлар тудыру.

T – 2019-2021 еллар – вакытта чикләнгәнлек.

Максаттан түбәндәге бурычлар килеп чыга:

- район территориясендә яшәүче барлык категория яшьләрнең мәнфәгатьләрен һәм проблемаларын өйрәнү ;
- район чикләрендә үсеш мөмкинлекләре турында яшьләрнең хәбәрдарлыгын арттырырга сәләтле чаралар системасын эшләү;
- яшьләрне хакимият органнары белән хезмәттәшлек итү юлы белән Ютазы районының социаль-икътисади үсешендә системалы катнашуына җәлеп итү;
- киләчәктә җирле үзидарә органнарында эшләү очен яшьләрнең иң актив өлешен ачыклау.

## 4 бүлек. Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары

Программаны тормышка ашыру өч елга – 2019-2021 елларга исәпләнгән.

**5бүлек. Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары Программаны финанслау структурасы**

Программаны финанслау муниципаль һәм республика бюджеты хисабына гамәлгә ашырыла, шул исәптән грантларда катнашу, җәлеп ителгән акчалар, шул исәптән химаячелек ярдәме белән җәлеп ителгән акчалар хисабына гамәлгә ашырыла.

| Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | |
|---|---|---|---|
| | 1-нче ел/ мең сум | 2-нче ел/ мең сум | 3-нче ел/ мең сум |
| Муниципаль бюджет | 4995,1 | 4995,1 | 4995,1 |
| Республика бюджеты | 140,0 | 140,0 | 140,0 |
| Җәлеп ителгән акчалар | 50,0 | 50,0 | 50,0 |
| Барлыгы | 5 185,1 | 5 185,1 | 5 185,1 |
| | | Бөтенесе, мең сум | **15 555,3** |

## 6 бүлек. Программа чаралары системасы

Программа чаралары яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендә хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең база (тармак) исемлеге, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив документлары нигезендә билгеләнгән.

Программа чаралары системасы түбәндәге юнәлешләр буенча эшләрне берләштерә:

-Яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләрне гражданлык һәм патриотик тәрбияләүгә, яшьләр арасында толерантлык тәрбияләүгә, экстремизм һәм терроризмны кисәтүгә, яшьләр арасында хокукый, мәдәни һәм әхлакый кыйммәтләр булдыруга юнәлтелгән чаралар оештыру;

-Яшьләр арасында асоциаль күренешләрне кисәтүгә, спортны популярлаштыруга, яшьләрнең ялын яхшыртуга һәм сәламәтләндерүгә юнәлдерелгән яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар оештыру.

-Яшьләр һәм балалар иҗтимагый оешмалары, яшьләр парламенты, авыл һәм эшче яшьләр белән эшләүне камилләштерүгә, ирекләләр хәрәкәтен үстерүгә юнәлдерелгән яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар оештыру.

**7 бүлек. Программаны тормышка ашыру барышын финанслау һәм контрольдә тотуны оештыру тәртибе**

Программаның үтәлешен "Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге» МКУ гомуми контрольдә тота, ул максатчан күрсәткечләрне, программаны тормышка ашыру механизмын, башкаручыларның составын аныклый, бер елда программаның үтәлеше һәм финанс чараларын куллануның нәтиҗәлелеге буенча эш барышы турында хәбәр итә.

**8 бүлек. Нәтиҗәлелекне бәяләү индикаторлары**

Программаны тормышка ашыру күрсәткече нәтиҗәлелек индикаторлары белән билгеләнә:

| № т/б | Күрсәткечләр төре | Исәпләү формуласы | Чыганак | 2018 ел(отчет) | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| 1 | Районнан китүче 14 яшьтән 30 яшькә кадәр яшьләрнең чагыштырма дәрәҗәсе, % | Чагыштырма дәрәҗә түбәндәге формула буенча исәпләнә: $C = \frac{C_1 \times 100\%}{C_2}$ биредә $C_1$ - 14 яшьтән 30 яшькә кадәр китүче яшьләр саны; $C_2$ - районнан киткән халыкның гомуми саны. | Рәсми статистика мәгълүматлары | 49% | 46% | 43% | 40% |
| 2 | Программа чараларына җәлеп ителгән 14 яшьтән 30 яшькә кадәр мәшгуль яшьләрнең чагыштырма дәрәҗәсе, % | Чагыштырма дәрәҗә түбәндәге формула белән исәпләнә: $B = \frac{B_1 \times 100\%}{B_2}$ Биредә $B_1$ – 14 яшьтән 30 яшькә кадәр чараларга җәлеп ителгән яшьләр саны; $B_2$ - 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге район яшьләренең гомуми саны. | Яшьләр белән эшләү буенча учреждениеләрнең чаралардан отчетлары | 32% | 36% | 40% | 45% |

## 9 бүлек. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре

Программаны гамәли тормышка ашыру тәэмин итәргә тиеш:
- район яшьләренә яшәү һәм үзләрен социаль яктан күрсәтү өчен уңай шартлар тудыруны;
- интеллектуаль, әхлакый һәм иҗат потенңиалын арттыруны, милли үзаңны, яшьләрнең гражданлыгын һәм патриотлыгын үстерүне;
- яшь гражданнарга мәгълүмати хезмәт күрсәтүне киңәйтүне;
- райондагы социаль-икътисадый үзгәртеп коруларда яшьләрнең ролен арттыруны;
- яшьләрнең хезмәт, мәшгульлек һәм һөнәри юнәлеш базарында конкурентлыкка сәләтлелеген арттыруны, яшьләрнең эшлекле активлыгын арттыруны һәм эшлеклелеген арттыруны.

Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткече булып яшьләр арасында Ютазы районының җәлеп итүчәнлеген арттыру, районда һөнәри үсеш һәм үз потенциалын тормышка ашыру, шулай ук район яшьләренең социаль активлыгын күтәрү мөмкинлекләре турында хәбәрдарлыгы тора.

## Программаның оештыру чаралары

| № | Чараның исеме | Башкару срогы | Башкаручылар | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикаторларның әһәмияте | | | Шул исәптән, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2019 | 2020 | 2021 |
| 1. | Яшьләр сәясәте учреждениеләре хезмәткәрләренең эш хакы | Ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге (ОДМСиТ) | - | - | - | - | 4 418,4 | 4 418,4 | 4 418,4 |
| *Яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләрне гражданлык һәм патриотик тәрбияләүгә, яшьләр арасында толерантлык тәрбияләүгә, экстремизмны һәм терроризмны профилактикалауга, яшьләр арасында хокукый, мәдәни һәм әхлакый кыйммәтләр булдыруга юнәлтелгән чаралар оештыру* | | | | | | | | | | |
| | | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2019 | 2020 | 2021 |
| 2. | “Армейский призыв” тантаналы район чарасын уздыру – призывникларны хөрмәтләү | Елга 2 тапкыр | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге(ОДМСиТ) | Чарага җәлеп ителгән кешеләр саны, кеше | 45 | 55 | 60 | 50,0 | 50,0 | 75,0 |
| 3. | Үсмерләр, укучы һәм эшче яшьләр арасында “Аҗаган” хәрби-спорт уенын оештыру һәм уздыру | Елга бер тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Чарага җәлеп ителгән кешеләр саны, кеше | 90 | 100 | 110 | 30,0 | 30,0 | 55,0 |
| 4. | Яшәү урыны буенча өмәләр уздыруны оештыру һәм үткәрү, клумбалар ясау, агач үсентеләре утырту, Хәтер мемориалларын җыештыру | Ел дәвамында, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Үткәрелгән өмәләр саны<br>Чарага җәлеп ителгән кешеләр саны | 7<br>30 | 10<br>35 | 12<br>40 | - | - | - |
| 5. | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан | Ел | Яшьләр | Уздырылган | 10 | 12 | 15 | 65,0 | 65,0 | 75,0 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | сугышында Җиңү еллыгына, Ватанны саклаучылар көненә багышланган спорт чаралары уздыру | дәвамында, ел саен | эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | ярышлар саны<br><br>Чарага җәлеп ителгән кешеләр саны | 45 | 55 | 70 | | | |
| 6. | «Обыкновенный фашизм», «Список Шиндлера» һәм башка видеоматериалларны файдаланып, укучылар өчен әңгәмәләр һәм чаралар уздыру | Елга 2 тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Үткәрелгән әңгәмәләр саны<br><br>Чарага җәлеп ителгән укучылар саны. | 2<br><br>40 | 2<br><br>50 | 2<br><br>55 | - | - | - |
| *Яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләрне гражданлык һәм патриотик тәрбияләүгә, яшьләр арасында толерантлык тәрбияләүгә, экстремизмны һәм терроризмны профилактикалауга, яшьләр арасында хокукый, мәдәни һәм әхлакый кыйммәтләр булдыруга юнәлтелгән чаралар оештыру* | | | | | | | | | | |
| | | | | | **2019** | **2020** | **2021** | **2019** | **2020** | **2021** |
| 7. | Яшьләр һәм үсмерләр мохитында асоциаль күренешләрне кисәтү буенча район акцияләре уздыру | Ел дәвамында, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Уздырылган акцияләр саны<br>Акциягә җәлеп ителгән кешеләр саны | 4<br><br>30 | 5<br><br>40 | 6<br><br>50 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 8. | «СТОП ВИЧ/СПИД» бөтенроссия акциясен уздыру | Елга бер тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Акциягә җәлеп ителгән кешеләр саны | 20 | 25 | 30 | 3,0 | 3,0 | 3,0 |
| 9. | Кызлар һәм егетләр арасында стритбол буенча турнир | Елга бер тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Чарага җәлеп ителгән кешеләр саны | 40 | 45 | 50 | 7,0 | 7,0 | 7,0 |
| 10. | Егетләр арасында воркаут буенча турнир | Елга бер тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт | Чарага җәлеп ителгән | 10 | 15 | 20 | 9,0 | 9,0 | 9,0 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | һәм туризм бүлеге | кешеләр саны | | | | | | |
| 11. | Урыссу җиңел атлетика йөгереше | Елга бер тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Чарага җәлеп ителгән кешеләр саны | 150 | 170 | 190 | 30,0 | 30,0 | 30,0 |
| 12. | Кызлар һәм егетләр арасында волейбол буенча беренчелек | Елга бер тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Чарага җәлеп ителгән кешеләр саны. | 20 | 30 | 40 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| 13. | Егетләр арасында хоккей сөючеләр турниры | Елга бер тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Чарага җәлеп ителгән кешеләр саны | 20 | 30 | 40 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 14. | Район велоузышы | Елга бер тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Чарага җәлеп ителгән кешеләр саны. | 70 | 90 | 100 | 20,0 | 20,0 | 20,0 |
| 15. | Ютазы муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең җәйге ялын, мәшгульлеген, сәламәтләндерелүен оештыру Программасын гамәлгә ашыруда ктнашу | Ел саен, җәй | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Җәйге ялга җәлеп ителгән кешеләр саны | 300 | 350 | 400 | 80,0 | 80,0 | 80,0 |
| 16. | Ютазы районы буенча экскурсион маршрут оештыру | Ел саен, җәй | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Экскурсиягә җәлеп ителгән кешеләр саны | 20 | 30 | 30 | 40,0 | 40,0 | 40,0 |
| *Яшьләр һәм балалар иҗтимагый оешмалары, яшьләр парламенты, авыл һәм эшче яшьләр белән эшләүне камилләштерүгә, ирекләләр хәрәкәтен үстерүгә юнәлдерелгән яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар оештыру* | | | | | | | | | | |
| | | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2019 | 2020 | 2021 |
| 17. | Яшьләр һәм балалар иҗтимагый | Квартал | Яшьләр | Киңәшмәдә | 15 | 20 | 20 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | оешмалары лидерлары белән киңәшмәләр уздыру | саен, ел саен | эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | катнашкан кешеләр саны | | | | | | |
| 18. | ЮМР Башлыгының яшьләр һәм балалар иҗтимагый оешмалары белән очрашулар уздыруы | Елга 2 тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Чарага җәлеп ителгән кешеләр саны | 20 | 20 | 20 | - | - | - |
| 19. | Район талантлы яшьләренең һәм яшьләр активының мәгълүмати базасын булдыру | Ел дәвамында, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Мәгълүматлар базасына кертелгән кешеләр саны | 50 | 55 | 60 | - | - | - |
| 20. | Яшьләр көнен бәйрәм иткәндә, яшьләр лидерларын хөрмәтләү | Елга бер тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Яшьләр лидерлары саны | 5 | 10 | 15 | 100,7 | 100,7 | 100,7 |
| 21. | Яшь лидерларны ачыклау, укыту һәм аларга булышу | Ел дәвамында, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Уку узган яшь лидерлар саны. | 5 | 10 | 15 | 15,0 | 15,0 | 15,0 |
| 22. | Яшьләр форумын уздыру | Елга бер тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Чарага җәлеп ителгән кешеләр саны. | 40 | 50 | 60 | 70,0 | 70,0 | 70,0 |
| 23. | Авыл яшьләре арасыннан Ютазы муниципаль районы вәкаләтле органнарына депутатлыкка кандидатлар әзерләү (тренинглар, семинарлар, курслар, яшь сәясәтче мәктәбе, мәгълүмат бирү, күнекмәләр) | Елга 2 тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Депутатлыкка кандидатлар саны | 2 | 3 | 5 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| 24. | «Авыл яшьләре» яшьләр хәрәкәтен оештыру һәм аның эше | Ел дәвамында, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Хәрәкәткә җәлеп ителгән кешеләр саны | 10 | 15 | 15 | 20,0 | 20,0 | 20,0 |
| 25. | Ютазы районы авыл яшьләр лидерларының республика авыл | Ел дәвамында | Яшьләр эшләре, | Чарага җәлеп | 2 | 2 | 2 | 2,0 | 2,0 | 2,0 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | яшьләре Форумында катнашуларын оештыру | а, ел саен | спорт һәм туризм бүлеге | ителгән кешеләр саны | | | | | | |
| 26. | "ТР аграр яшьләр берләшмәсе" төбәк иҗтимагый оешмасының район бүлеген оештыру | Ел дәвамында, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Хәрәкәткә җәлеп ителгән кешеләр саны | 10 | 10 | 10 | - | - | - |
| 27. | Авыл яшьләренең социаль актив өлешеннән кадрлар резервы мәгълүматлар базасын булдыру | Ел дәвамында, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Мәгълүматлар базасына кертелгән кешеләр саны | 10 | 15 | 15 | - | - | - |
| 28. | "Һөнәре буенча иң яхшы" исеменә эшче яшьләр арасында һөнәр осталык конкурсы уздыру | Елга бер тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Чарага җәлеп ителгән кешеләр саны | 10 | 10 | 10 | 20,0 | 20,0 | 20,0 |
| 29. | Район эшче яшьләр слетын уздыруны оештыру һәм үткәрү | Елга бер тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Чарага җәлеп ителгән кешеләр саны. | 45 | 50 | 60 | 45,0 | 45,0 | 45,0 |
| 30. | Эшче яшьләрнең КВН уеннарын оештыру һәм уздыру | Елга бер тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Чарага җәлеп ителгән кешеләр саны | 30 | 35 | 40 | 15,0 | 15,0 | 15,0 |
| 31. | "Яшьләргә – эш!" район акциясен, яшьләр өчен күчмә вакансияләр ярминкәсен уздыру | Ел дәвамында, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Чарага җәлеп ителгән кешеләр саны | 45 | 50 | 60 | 3,0 | 3,0 | 3,0 |
| 32. | «Политзавод», «Кадрлар резервы», «Вверх!»<br>«Түгәрәк өстәлләр», «Безнен заман» чараларының зональ этапларын оештыру, уздыру һәм республика этапларында катнашу | Ел дәвамында, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Чарага җәлеп ителгән кешеләр саны<br>Зональ этапта үткәрелгән чаралар | 30<br>3 | 40<br>4 | 50<br>5 | 70,0 | 70,0 | 70,0 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | саны | | | | | | |
| 33. | Яшьләр парламенты утырышы | Кварталга 1 тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Үткәрелгән утырышлар саны | 4 | 4 | 4 | - | - | - |
| 34. | Язгы игелеклелек атнасы”, “Көзге игелеклелек атнасы” республика ирекле акцияләре кысаларында чаралар | Елга 2 тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Чарага җәлеп ителгән кешеләр саны<br>Үткәрелгән акцияләр саны | 30<br>4 | 40<br>6 | 50<br>8 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 35. | Ирекле отрядлар уздырган чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында (ММЧ) яктырту | Ел дәвамында, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | ММЧда басмалар саны | 6 | 8 | 10 | - | - | - |
| 36. | “Хәтер шәме” бөтенроссия ирекле акциясен уздыру | Елга бер тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Чарага җәлеп ителгән кешеләр саны | 40 | 50 | 60 | 7,0 | 7,0 | 7,0 |
| 37. | *Россиядә Доброволец (волонтер) көнен бәйрәм итү кысаларында чаралар уздыру* | Елга бер тапкыр, ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Чарага җәлеп ителгән кешеләр саны | 40 | 50 | 60 | 25,0 | 25,0 | 25,0 |
| | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | **Барлыгы:** | 5 185,1 | 5 185,1 | 5 185,1 |